**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» июль, 2022 ел № 467

2022 елның икенче яртыеллыгына салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыгының 2022 елның 15 февралендәге 62 номерлы хаты белән Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елның икенче яртыеллыгына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 2 506 564 сум
1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 3 190 173 сум
1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 4 101 651 сум
1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 5 468 868 сум
1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 6 836 085 сум
1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 8 203 302 сум
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 9 570 519 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 27 369  сум
1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 17 417 сум
1.2.3.  Өч кешелек гаилә өчен - 14 928 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондын исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемле дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хабибуллин